| ГЛАВА<br>Красноборского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Красный Бор авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2024 Красный Бор авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Красный Бор авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республтикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный бор авыл җирлеге Башлыгы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Красный Бор торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2024 елның 15 ноябренә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Красный Бор торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2024 елның 15 ноябренә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

1 этап: Восточная ур., Гора Марс ур., Новая ур., Красноборская ур., Коммунальная ур., Песочная ур., Подгорная ур, Речная ур., Маркина ур. 1 нче йорттан 27 нче йортка кадәр, Юности ур., Гагарина ур., Набережная ур., Спортивная ур., Трудовая ур., Заречная ур.

2 этап: Маркин ур. 37 нче йорттан 63 нче йортка кадәр, Строителей ур., Горная ур, Лесная ур, Камская ур, М. Горького ур, Совхозная ур, Молодежная ур, Сельхозтехники ур., Октябрьская ур, Толстого ур.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: «2025 Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районнының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Красный Бор торак пункты территориясендә, I, II төркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткән),

көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче әти-әниләре, хатыннары, балигъ булган балаларны)түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркелгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә узара салым чаралары жыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны жыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү),

2) торак пункт территориясен төзекләндерү, музей өчен җиһазлар сатып алу һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар;

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, фонарьлар сатып алу һәм алмаштыру; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

5) пычкы һәм аңа комплектлаучы әйберләр сатып алу;

6) янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар жыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Красный Бор авылы, Маркин урамы, 34 йорт адрес буенча авыл мәдәният йортында уздырырга:

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка житкерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Е.А. Яковлева

Совет Краснооборского сельского поселения
Красный Бор авыл жирлеге Советы
ИНН 1601002434